Республика Татарстан

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**
**«ЛЕНИНОГОРСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»**

Татарстан Республикасы

**«ЛЕНИНОГОРСК**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» 02 2014 № 24

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 17 сентябрендәге 357 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү Тәртибенә түбәндәге өстәмәне кертергә:

2 бүлекнең 2.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:

«Гражданнар тарафыннан торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә элек билгеләнгән субсидияләр яисә балага айлык пособие алган очракта, гражданин гаризасы буенча компенсация субсидия яки балага айлык пособие бирү срогы тәмамланганчы билгеләнә ала.

Әгәр компенсация алучы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә субсидия яки айлык балалар пособиесе билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән граждан гаиләсе составына керсә, элек билгеләнгән компенсация, алучы гаризасы буенча, субсидия алу яисә бала өчен айлык пособие алу чорына, субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларны йә айлык балалар пособиесен исәпкә алып, яңадан билгеләнергә мөмкин.».

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.А.ХИСМӘТУЛЛИН

Я.З.Хәйров
5-12-15